Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Умга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

17 ноябрь 2022 ел № 1

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның «17» ноябрендә 16 сәгать 00 минутта, 2022 елның «17» ноябрендә 18 сәгать 00 минутта булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Умга торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы":

1. Сарсак-Умга авылы өчен вак таш сатып алу һәм гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау, килешү буенча эш өчен түләү;

2. Сарсак-Умга авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен тирәнтен насос, торбалар һәм башка материаллар сатып алу, ремонтлау, хезмәт күрсәтү;

3. Күмү урыннарын оештыру, төзелеш материалларын сатып алу һәм зират коймасын тоту, һәйкәл ясау һәм килешү буенча эш өчен түләү;

4. Улән чабу өчен триммер һәм аңа насадкалар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;

5. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, дизель ягулыгы, май һәм запас частьләр сатып алу, урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 412 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 217 кеше, бу – 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 217 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сарсак-Умга торак пунктында

гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Сарсак-Умга авыл җирлеге» Сарсак-Умга торак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш ирektән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Сарсак-Умга авылында вак таш сатып алу һәм гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау, килешү буенча эш өчен түләү;

2. Сарсак-Умга авылында халыкны су белән тәэмин итү өчен тирәнтен насос, торбалар һәм башка материаллар сатып алу, ремонтлау, хезмәт күрсәтү;

3. Күмү урыннарын оештыру, төзелеш материалларын сатып алу һәм зират коймасын тоту, һәйкәл ясау һәм килешү буенча эш өчен түләү;

4. Улән чабу өчен триммер һәм аңа насадкалар сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;

5. МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, дизель ягулыгы, май һәм запас частьләр сатып алу, урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С.Николаева